**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**О грантах Республики Татарстан, предоставляемых на развитие гражданского общества**

В целях обеспечения государственной поддержки некоммерческих организаций, участвующих в развитии гражданского общества, реализующих социально значимые проекты и проекты в сфере защиты прав и свобод человека и гражданина, **постановляю:**

1. Утвердить прилагаемое Положение о грантах Республики Татарстан, предоставляемых на развитие гражданского общества.

2. Предоставлять ежегодно автономной некоммерческой организации «Республиканский ресурсный центр по поддержке социально ориентированных некоммерческих организаций» субсидию в пределах бюджетных ассигнований, предусмотренных в бюджете Республики Татарстан на соответствующий финансовый год и плановый период Министерству экономики Республики Татарстан на поддержку некоммерческих организаций, участвующих в развитии гражданского общества.

3. Кабинету Министров Республики Татарстан:

утвердить порядок предоставления субсидии, указанной в пункте 2 настоящего Указа, для проведения конкурсов на предоставление грантов Республики Татарстан некоммерческим организациям, участвующим в развитии гражданского общества, на реализацию социально значимых проектов и проектов в сфере защиты прав и свобод человека и гражданина, срок реализации которых составляет не более трех лет;

образовать Республиканскую комиссию по проведению конкурсов на предоставление грантов Республики Татарстан на развитие гражданского общества;

утвердить положение о Республиканской комиссии по проведению конкурсов на предоставление грантов Республики Татарстан на развитие гражданского общества и ее состав;

привести свои акты в соответствие с настоящим Указом, а также принять иные решения, обеспечивающие его реализацию.

4. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
29 декабря 2021 года
№ УП-1002

Утверждено
Указом Президента
Республики Татарстан

от « 29 » декабря 2021 года

№ УП-1002

**Положение**
**о грантах Республики Татарстан, предоставляемых**
**на развитие гражданского общества**

1. Целью предоставления грантов Республики Татарстан на развитие гражданского общества (далее – гранты) является обеспечение государственной поддержки некоммерческих организаций, участвующих в развитии гражданского общества (далее – некоммерческие организации).

2. Гранты предоставляются некоммерческим организациям, реализующим социально значимые проекты и проекты в сфере защиты прав и свобод человека и гражданина, осуществляющим деятельность по следующим направлениям:

а) социальное обслуживание, социальная поддержка и защита граждан;

б) охрана здоровья граждан, пропаганда здорового образа жизни;

в) поддержка семьи, материнства, отцовства и детства;

г) поддержка молодежных проектов, реализация которых охватывает виды деятельности, предусмотренные статьей $31^1$ Федерального закона от 12 января 1996 года № 7-ФЗ «О некоммерческих организациях»;

д) поддержка проектов в области науки, образования, просвещения;

е) поддержка проектов в области культуры и искусства;

ж) выявление и поддержка молодых талантов в области культуры и искусства;

з) сохранение исторической памяти;

и) защита прав и свобод человека и гражданина, в том числе защита прав заключенных;

к) охрана окружающей среды и защита животных;

л) укрепление межнационального и межрелигиозного согласия;

м) развитие общественной дипломатии и поддержка соотечественников;

н) развитие институтов гражданского общества.

3. Гранты, предусмотренные пунктом 2 настоящего Положения, предоставляются некоммерческим организациям по результатам конкурсов, которые проводятся автономной некоммерческой организацией «Республиканский ресурсный центр по поддержке социально ориентированных некоммерческих организаций» (далее – грантооператор) совместно с Республиканской комиссией по проведению конкурсов на предоставление грантов Республики Татарстан на развитие гражданского общества, образуемой Кабинетом Министров Республики Татарстан (далее – Республиканская комиссия).

4. Конкурсы на предоставление грантов (далее – конкурсы) проводятся не реже одного раза в год.

5. В связи с подготовкой и проведением конкурсов грантооператор осуществляет следующие виды деятельности:

а) определяет по согласованию с Республиканской комиссией сроки проведения конкурсов;

б) утверждает по согласованию с Республиканской комиссией положения о конкурсах, определяющие условия и порядок их проведения;

в) обеспечивает прозрачность и открытость проведения конкурсов;

г) обеспечивает информационное сопровождение конкурсов;

д) организует в соответствии с решениями Республиканской комиссии проведение независимой экспертизы представленных на конкурсы проектов;

е) определяет по согласованию с Республиканской комиссией с учетом результатов независимой экспертизы представленных на конкурсы проектов объем средств, необходимых для проведения каждого конкурса, и утверждает перечни некоммерческих организаций – победителей конкурсов;

ж) предоставляет гранты некоммерческим организациям – победителям конкурсов;

з) организует мониторинг реализации социально значимых проектов и проектов в сфере защиты прав и свобод человека и гражданина, осуществляет оценку их результатов, в том числе социального эффекта;

и) оказывает информационную, консультационную и методическую поддержку некоммерческим организациям при разработке и реализации ими социально значимых проектов и проектов в сфере защиты прав и свобод человека и гражданина;

к) обеспечивает формирование информационных ресурсов, содержащих сведения о деятельности и механизмах поддержки некоммерческих организаций.

6. Гранты предоставляются за счет средств субсидии, ежегодно предусматриваемой в бюджете Республики Татарстан на поддержку некоммерческих организаций, участвующих в развитии гражданского общества, а также за счет средств, привлекаемых грантооператором из внебюджетных источников.

7. Грантооператор обеспечивает целевое расходование субсидии и представляет в Министерство экономики Республики Татарстан соответствующий отчет.

---

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Граждан җәмгыятен үстерүгә бирелә торган Татарстан Республикасы грантлары турында**

Социаль әһәмияткә ия проектларны, кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау өлкәсендә проектларны тормышка ашыра торган граждан җәмгыятен үстерүдә катнашучы коммерциячел булмаган оешмаларга дәүләт ярдәмен тәэмин итү максатында **карар бирәм:**

1. Кушымтада китерелгән Граждан җәмгыятен үстерүгә бирелә торган Татарстан Республикасы грантлары турында нигезләмәне расларга.

2. Ел саен «Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга ярдәм итү республика ресурс үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасына Татарстан Республикасы бюджетында тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына граждан җәмгыятен үстерүдә катнашучы коммерциячел булмаган оешмаларга ярдәм итүгә каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә субсидия бирергә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

аларны тормышка ашыру вакыты өч елдан артып китмәгән социаль әһәмияткә ия проектларны, кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау өлкәсендә проектларны тормышка ашыра торган, граждан җәмгыятен үстерүдә катнашучы коммерциячел булмаган оешмаларга Татарстан Республикасы грантларын бирүгә конкурслар уздыру өчен әлеге Указның 2 пунктында күрсәтелгән субсидияләр бирү тәртибен расларга;

Татарстан Республикасы грантларын бирүгә конкурслар уздыру буенча республика комиссиясе төзергә;

Татарстан Республикасы грантларын бирүгә конкурслар уздыру буенча республика комиссиясе турында нигезләмәне һәм аның составын расларга;

үз актларын әлеге Указга туры китерергә, шулай ук аны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче башка карарлар кабул итәргә.

4. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** — **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2021 ел, 29 декабрь
№ ПУ-1002

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ

Татарстан Республикасы
Президентының
2021 елның « 29 » декабрендәге
ПУ- 1002 номерлы Указы белән
расланды

**Граждан җәмгыятен үстерүгә бирелә торган Татарстан Республикасы грантлары турында нигезләмә**

1. Граждан җәмгыятен үстерүгә Татарстан Республикасы грантларын (алга таба – грантлар) бирүнең максаты – граждан җәмгыятен үстерүдә катнашучы коммерциячел булмаган оешмаларга (алга таба – коммерциячел булмаган оешмалар) дәүләт ярдәмен тәэмин итү.

2. Грантлар социаль әһәмияткә ия проектларны, кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау өлкәсендә проектларны тормышка ашыра торган коммерциячел булмаган оешмаларга бирелә, алар түбәндәге юнәлешләр буенча эшчәнлек алып бара:

а) гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү, аларны социаль яклау;

б) гражданнарның сәламәтлеген саклау, сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау;

в) гаиләгә, ата-аналарга һәм балаларга ярдәм итү;

г) аларны тормышка ашыру «Коммерциячел булмаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль законның $31^1$ статьясында каралган эшчәнлек төрләрен тәшкил иткән яшьләр проектларына ярдәм итү;

д) фән, мәгариф, мәгърифәт өлкәсендә проектларга ярдәм итү;

е) мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә проектларга ярдәм итү;

ж) мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә яшь талантларны ачыклау һәм аларга ярдәм итү;

з) тарихи хәтерне саклау;

и) кеше һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен, шул исәптән иректән мәхрүм ителгәннәрнең хокукларын яклау;

к) әйләнә-тирә мохитне һәм хайваннар дөньясын саклау;

л) милләтләр һәм диннәр арасында татулыкны ныгыту;

м) иҗтимагый дипломатияне үстерү һәм ватандашларга булышлык күрсәтү;

н) граждан җәмгыяте институтларын үстерү.

3. Әлеге Нигезләмәнең 2 пунктында каралган грантлар коммерциячел булмаган оешмаларга «Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга ярдәм итү республика ресурс үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасы (алга таба – грант операторы) һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан оештырылган Граждан җәмгыятен үстерүгә Татарстан Республикасы грантларын бирүгә конкурслар

уздыру республика комиссиясе (алга таба – Республика комиссиясе) белән берлектә уздырыла торган конкурслар йомгаклары буенча бирелә.

4. Грантлар бирүгә конкурслар (алга таба – конкурслар) кимендә елга бер тапкыр уздырыла.

5. Конкурсларны әзерләү һәм уздыру белән бәйле рәвештә грант операторы түбәндәге эшчәнлек төрләрен башкара:

а) Республика комиссиясе белән килештереп, конкурсларны уздыру вакытын билгели;

б) Республика комиссиясе белән килештереп, конкурсларның шартларын һәм аларны уздыру тәртибен билгели торган нигезләмәләрне раслый;

в) конкурслар уздыру турында мәгълүматның һәркемгә аңлаешлы һәм ачык булуын тәэмин итә;

г) конкурсларны мәгълүмати яктан тәэмин итә;

д) Республика комиссиясе карарлары нигезендә конкурска тәкъдим ителгән проектларга бәйсез экспертиза уздыруны оештыра;

е) конкурска тәкъдим ителгән проектларга бәйсез экспертиза уздыру йомгаклары нигезендә Республика комиссиясе белән килештереп, һәрбер конкурсны уздыру өчен кирәкле акчаның күләмен билгели һәм конкурсларда җиңгән коммерциячел булмаган оешмалар исемлеген раслый;

ж) конкурсларда җиңгән коммерциячел булмаган оешмаларга грантлар бирә;

з) социаль әһәмияткә ия проектларның, кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау өлкәсендә проектларның тормышка ашырылуына мониторингны оештыра, аларның йомгакларын, шул исәптән социаль өлкәдәге үзгәрешләрне бәяли;

и) коммерциячел булмаган оешмаларга социаль әһәмияткә ия проектларны, кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау өлкәсендә проектларны эшләгәндә һәм тормышка ашырганда мәгълүмати, консультация һәм методика ярдәме күрсәтә;

к) коммерциячел булмаган оешмалар эшчәнлеге һәм аларга ярдәм итү механизмнары турында мәгълүмат кертелгән мәгълүмати ресурслар формалаштыруны тәэмин итә.

6. Грантлар ел саен Татарстан Республикасы бюджетында граждан җәмгыятен үстерүдә катнашучы коммерциячел булмаган оешмаларга ярдәм итүгә каралган субсидия акчалары хисабыннан, шулай ук бюджеттан тыш чыганаклардан грант операторы тарафыннан җәлеп ителгән акчалар хисабыннан бирелә.

7. Грант операторы субсидиянең максатчан файдаланылуын тәэмин итә һәм Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына тиешле хисапны тапшыра.